# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
# БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

« 24 » сентябрь 2020 ел                                    № 8

Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе һәм Башкарма комитеты вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәжәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәжәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Сәмәкәй авыл жирлеге уставы нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Сәмәкәй авыл җирлеге вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен расларга (алга таба – тәртип).

2. Сәмәкәй авыл җирлегенең җирле үзидәрә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча әлеге тәртибКә таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

3. Гражданнар мөрәҗәгате буенча эш оештыруны, аларны үз вакытында карауны һәм үтәлешен контрольдә тоту тотуны Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенә (башлыгына) йөкләргә.

4. Җаваплы затларны билгеләргә:

- гражданнар мөрәжәгатьләрен, шул исәптән шәхси кабул итү вакытында кергән, авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына почта элемтәсе, электрон документ әйләнеше системасы, муниципаль районның интернет-кабул итү бүлмәсе аша язмача килгән гражданнар мөрәжәгатьләрен үз вакытында теркәү, гражданнарның язма мөрәҗәгатьләрен үз вакытында карау һәм аларның үтәлешен контрольдә тоту буенча вазыйфаи бурычлары нигезендә Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Абзалутдинова Светлана Вениамин кызын.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районын рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Сәмәкәй авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе                                    И.М.Усманов

Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетынын 2020 елның 24 сентябрь 8 номерлы карарына кушымта

**Сәмәкәй авыл җирлеге вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибе**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Сәмәкәй авыл җирлеге вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карауның һәм шәхси кабул итүнең әлеге тәртибе (алга таба – тәртип) «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге тәртип белән Россия Федерациясе гражданының (алга таба – граждан) Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе белән беркетелгән җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хокукын гамәлгә ашыруга бәйле хокукый мөнәсәбәтләр җайга салына, шулай ук Сәмәкәй авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары (алга таба – орган һәм вазыйфаи затлар) тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе билгеләнә.

**2. Әлеге нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр**

2.1. Граждан мөрәҗәгате (алга таба – мөрәҗәгать) – җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә яисә электрон документ формасында җибәрелгән тәкъдим, гариза яки шикаять, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгате;

2.2. тәкъдим – гражданның законнарны һәм башка норматив хокукый актларны, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үстерү, дәүләт һәм җәмгыять эшчәнлегенең социаль-икътисадый һәм башка өлкәләрен яхшырту буенча рекомендациясе;

2.3. гариза – гражданның аның конституция хокукларын һәм ирекләрен яки башка затларның конституция хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итү турында үтенече, яисә законнар һәм башка норматив хокукый актлар бозылу, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар эшендәге җитешсезлекләр турында хәбәр итү, яисә күрсәтелгән органнарның һәм вазыйфаи затларның эшчәнлегенә тәнкыйть;

2.4. шикаять – гражданның бозылган хокукларын, ирекләрен яки законлы мәнфәгатьләрен яисә башка затларнын хокукларын, ирекләрен яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яисә яклау турында үтенече;

2.5. вазыйфаи зат – хакимият вәкиле функцияләрен даими, вакытлыча яисә махсус вәкаләт буенча башкаручы яисә җирле үзидарә органында оештыру - идарә итү, административ - хуҗалык функцияләрен башкаручы зат.

2.6. коллектив мөрәҗәгать дигәндә ике яки аннан күбрәк гражданның, гражданнар, шул исәптән юридик затлар берләшмәләре мөрәҗәгате, шулай ук

тавыш бирү яки митингта яисә җыелышта катнашучыларның имзаларын җыю юлы белән кабул ителгән мөрәҗәгать аңлашыла.

## 3. Гражданнарның язма рәвештә язылган мөрәҗәгатьләре

3.1. Гражданнарның язмача мөрәҗәгатьләре тәкъдимнәр, гаризалар һәм шикаять рәвешендә керә.

3.2. Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгате мөрәҗәгать җибәрелә торган җирле үзидарә органының исемен һәм адресын яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, яисә тиешле затның вазыйфасын, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яки шикаятьнең асылын бәян итүне, үз фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысын – булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле почта адресын, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамәне, шәхси имзаны һәм датаны үз эченә алырга тиеш.

3.3. Органга яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать законнарда һәм әлеге тәртиптә билгеләнгәнчә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үз фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресын, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамәне мәҗбүри рәвештә күрсәтә. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада теркәргә хокуклы.

3.4. Гражданнар тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, туган телдә яки Россия Федерациясе халыкларының теләсә кайсы башка телендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Гражданнарның тәкъдимнәренә, гаризаларына, шикаятьләренә җавап мөрәҗәгать телендә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

3.5. Аларны хәл итү орган компетенциясенә керми торган мәсьәләләрне үз эченә алган язма мөрәҗәгатьләр, аларны теркәгәннән соң җиде көн эчендә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка, мөрәҗәгать җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәр итеп, әлеге тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән очрактан тыш, җибәрелә. Шул ук вакытта хәбәрнамәнең текстында Федераль законның тиешле статьясына сылтама булырга тиеш.

3.6. Язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү берничә орган яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керсә, мөрәҗәгатьнең күчермәсе теркәлгәннән соң җиде көн эчендә тиешле органнарга яисә тиешле вазыйфаи затларга җибәрелә.

3.7. Карарына яисә гамәл кылуына (гамәл кылмавына) дәгъва белдерелгән органга яисә вазыйфаи затка шикаятьне карауга җибәрү тыела.

3.8. Әлеге тыюга бәйле рәвештә, шикаятьне мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә керә торган органга яисә вазыйфаи затка җибәрү мөмкин түгел, шикаять тиешле карарга яисә гамәлгә (гамәл кылмауга) билгеләнгән тәртиптә судка шикаять бирү хокукын аңлатып, гражданга кире кайтарыла.

3.9. Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның яки шикаятьнең асылын билгеләргә мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул аларның компетенциясе нигезендә органга яисә вазыйфаи затка каралуга

җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң җиде көн эчендә мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә.

3.10. Мөрәҗәгать җибәргән гражданның фамилиясе яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы булмаган язма мөрәҗәгатькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, эшләнә торган яисә башкарылган хокукка каршы гамәл, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында мәгълүматлар булса, мөрәҗәгать теркәлергә һәм органга компетенциясе нигезендә җибәрелергә тиеш.

3.11. Гражданнар органның вазыйфаи затларына шәхсән яисә үз вәкиле аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.12. Суд карарына шикаять белдерелә торган мөрәжәгать, теркәлгән көннән җиде көн эчендә, әлеге суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, мөрәжәгать җибәргән гражданга кире кайтарыла.

3.13. Әгәр кергән мөрәҗәгатьтә әдәпсез яисә мәсхәрәле гыйбарәләр, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларынын тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, ул анда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта мөрәҗәгать җибәргән гражданга мөрәжәгать итү хокукын явыз ният белән куллануга юл куймау турында хәбәр ителә.

3.14. Гражданның язма мөрәжәгатендә элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә, аңа асылы буенча берничә тапкыр язма җаваплар бирелгән сорау булган, шул ук вакытта мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр яки хәлләр китерелмәгән очракта, күрсәтелгән мөрәжәгать һәм элек җибәрелгән мөрәжәгатьләр бер үк вазыйфаи затка берничә тапкыр юнәлтелгән шартта, вазыйфаи зат чираттагы мөрәжәгатьнең нигезсезлеге һәм әлеге мәсьәлә буенча граждан белән язылышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Бу карар турында мөрәжәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә.

3.14.1 Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә органның рәсми сайтында 3.3 пункты нигезендә урнаштырылган сорауны үз эченә алган мөрәҗәгать кергән очракта, мөрәжәгатьне теркәгән көннән җиде көн эчендә мөрәжәгатьне җибәргән гражданга Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мөрәҗәгатьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, шул ук вакытта суд карарына шикаять белдерелгән мөрәжәгать кире кайтарылмый.

3.15. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап дәүләт яки Федераль закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне игълан итмичә бирелергә мөмкин булмаган очракта, мөрәжәгать җибәргән гражданга әлеге мәгълүматларны хәбәр итү мөмкин булмауга бәйле рәвештә, анда куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

## 4. Гражданнарның язмача мөрәҗәгатьләрен кабул итү, теркәү һәм исәпкә алу

4.1. Почта җибәрүләрендә булырга мөмкин шартлаткыч, агулы һәм башка куркыныч әйберләрне үз вакытында ачыклау һәм йогышсызландыру максатында, аларны тышкы яктан карау үткәрелә. Мондый әйберләр ачыкланган яки аларнын булуына шик туган очракта, почта җибәрүләре белән алга таба һәр эш кичекмәстән туктатыла һәм куркынычсызлык органынын тиешле бүлекчәсе белгече чакырыла.

Белгеч чакырту белән бер үк вакытта почта җибәрүләрен мәҗбүри изоляциялэп, куркынычсызлык чаралары да күрелергә тиеш.

Террорчылык актларын һәм башка җинаятьләрне кылу куркынычы булган язма мөрәҗәгатьләрне алганда, оператив-эзләү чараларын һәм тикшерү гамәлләрен үткәргәндә файдаланылырга мөмкин булган эзләрне саклау өчен чаралар күрелә.

4.2. Язма мөрәҗәгатьләрне кабул иткәндә, аларнын адресларынын дөреслеге тикшерелә. Билгеләнеше буенча китерелмәгән хатлар ачылмаган хәлдә кичекмәстән элемтә почта предприятиесенә адресатка җибәрү өчен кире кайтарыла.

Конвертларны ачканда, аларда хат һәм конвертка теркәлгән документлар (ертылган документлар беркетелә) тикшерелә, кергән документлар (паспорт, хәрби билет, хезмәт кенәгәсе, пенсия таныклыгы һ.б., шулай ук фотографияләр һәм хатка башка кушымталар) хат текстының алдына скрепка белән беркетелә. Кушымта яки хат текстының юклыгы ачыкланган очракта, конвертка текркәлә торган белешмә төзелә һәм бу хакта гражданга хәбәр ителә.

4.3. Барлык язма мөрәҗәгатьләр органга яисә вазыйфаи затка кергән көннән өч көн эчендә теркәлә. Һәр мөрәҗәгатькә тәртип буенча теркәү номеры бирелә. Һәр яңа календарь елында яңадан кергән мөрәҗәгатьләрнең нумерациясе беренче номердан башлана.

4.4. Кәгазьдә кергән язма мөрәҗәгатьләр мәҗбүри рәвештә сканерлана һәм электрон документ әйләнеше системасына йөкләнә.

4.5. Граждан шикаятендә күрсәтелгән белешмәләр ахыргы карарны чыгару өчен җитәрлек булмаганда, гамәлләренә шикаять белдерелә торган учреждениедән яки заттан тикшерү материаллары, карар кабул итүнең нигезлелеге турында бәяләмә белән соратып алына.

4.6. Әгәр барлык сораулар каралса, алар буенча тиешле чаралар күрелсә һәм гамәлдәге законнарга туры килә торган тулы җаваплар бирелсә, гражданнарның хатлары хәл ителгән дип санала.

4.7. Башкаручы тарафыннан әзерләнгән мөрәҗәгатькә җавап проекты орган җитәкчесенә яки компетенцияләре нигезендә мөрәҗәгатьләргә җавапларны имзаларга вәкаләтле затларга кул куюга тапшырыла. Башкаручы (кул куйган затлар белән бер үк вакытта) җавапларның эчтәлеге, ачыклыгы һәм төгәллеге, норматив актларга сылтаманың дөреслеге өчен җаваплылыкка ия.

4.8. Органның вазыйфаи затлары:

а) мөрәҗәгатьне объектив, һәрьяклы һәм үз вакытында карауны тәэмин итәләр, кирәк булган очракта - мөрәҗәгать җибәргән граждан катнашында;

б) мөрәҗәгатьне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка вазыйфаи затлардан, шул исәптән электрон формада соратып алалар, судлардан, сорау алу органнарыннан һәм алдан тикшерү органнарыннан тыш;

в) гражданның бозылган хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен торгызуга яки яклауга юнәлдерелгән чаралар күрәләр;

г) мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча, әлеге тәртипнең 1.5, 1.6, 1.8, 1.9, 1.10, 1.11 пунктларында күрсәтелгән очраклардан тыш, язма җаваплар бирәләр;

д) гражданга аның мөрәҗәгатен башка дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә башка вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә карау өчен җибәрү турында хәбәр итәләр.

4.9. Мөрәҗәгатьне караганда, мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны, шулай ук гражданның шәхси тормышына кагылышлы мәгълүматларны анын ризалыгыннан башка хәбәр итү рөхсәт ителми. Мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән органга яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгать җибәрү мөрәҗәгатьтәге мәгълүматларны тарату булып тормый.

4.10. Гражданнарның язмача мөрәҗәгатьләре теркәү көненнән 30 көн эчендә карала.

4.11. Мөрәҗәгатьләрне карау срогы башлану дип аларны теркәү көне санала. Мөрәҗәгатьләрне карау срогы тәмамлану дип мөрәҗәгать авторына җавапка имза кую датасы санала.

4.12. Билгеләнгән тәртиптә каралган мөрәжәгатьләр буенча карарлар чикләнгән файдаланудагы хезмәт мәгълүматына керә алмый.

4.13. Язма мөрәҗәгатькә җавап орган житәкчесе тарафыннан аларнын компетенциясе нигезендә имзалана. Җавап граждан күрсәткән адреска җибәрелә.

Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ формасында мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча һәм язма формада кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән почта адресы буенча язма формада җибәрелә.

Моннан тыш, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагылган тәкъдимне, гаризаны яки шикаятьне үз эченә алган мөрәжәгатькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына карата шикаять белдерелә торган мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә органнын рәсми сайтында әлеге тәртипнең 4.11 пункты таләпләрен үтәп урнаштырылырга мөмкин.

## 5. Коррупция юнәлеше фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

5.1. Коррупциягә каршы хокук бозулар турында мәгълүмат ачыкланган мөрәҗәгатьне алдан карау процедурасын уздырганнан сон, мөрәҗәгать кичекмәстән орган житәкчесенә тапшырыла.

Җитәкче резолюцияләр куя һәм башкаручыларны билгели. Мөрәҗәгатьне карау аерым контрольгә куела.

5.2. Карары яки гамәл кылуы (кылмавы) мөрәҗәгать итү предметы булып торган органга яисә вазыйфаи затка мөрәҗәгать җибәрелми.

5.3. Мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, эшләнә торган яисә башкарылган хокукка каршы гамәл, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яки башкарган зат турында мәгълүматлар булса, мөрәҗәгать теркәлә һәм органга компетенциясе нигезендә җибәрелә.

5.4. Мөрәҗәгатьтә муниципаль хезмәткәр тарафыннан муниципаль хезмәт белән бәйле вазыйфаларны, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәү, шулай ук хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәмәү, муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык, мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү, муниципаль хезмәткәр тарафыннан башка коррупцион хокук бозулар кылу ихтималы турында мәгълүматлар булса, орган җитәкчесе кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе вазыйфаи затының (коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазыйфаи затларнын) доклад язмасы нигезендә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактларга карата тикшерү үткәрүнең

максатчанлыгы турында карар кабул итә. Әлеге тикшерү хезмәт тәртибе таләпләрен (муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләрне үтәү, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларны үтәү) үтәүне тикшерү булып тора һәм Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында нигезләмәгә таянып үткәрелә.

5.5. Мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактларны оператив-эзләү чараларын үткәрү юлы белән тикшерү зарур булса, мөрәҗәгатьне карау барышында оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт органнарына запрос җибәрелә.

5.6. Вәкаләтле органга кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгате әлеге тәртиптә билгеләнгәнчә каралырга тиеш.

5.7. Мөрәҗәгатьтә куелган барлык сораулар буенча гражданга җавап җибәргәннән соң, мөрәҗәгать контрольдән алына.

## 6. Гражданнарны шәхси кабул итүне оештыру

6.1 Гражданнарны шәхси кабул итү Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе, анын урынбасары тарафыннан үткәрелә.

6.2 Кабул итү урыны, кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр, гражданнарны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи затларның элемтә телефоннары турында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чаралары аша гражданнарга житкерелә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сәмәкәй авыл жирлегенең рәсми сайтында урнаштырыла. Әлеге мәгълүмат шулай ук Сәмәкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

6.3. Гражданнарны кабул итүне теркәү һәм исәпкә алуны органның оештыру эшләре бүлегенең эйдәп баручы белгече вазыйфаи бурычлары нигезендә гражданнарны кабул итүне исәпкә алу журналында (1 нче кушымта) алып бара. Телдән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеге гражданның шәхси кабул итү карточкасына (2 нче кушымта) кертелә, ул гражданны кабул итү датасы, анын фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), аның яшәү урыны, кабул итүне алып баручы вазыйфаи (вәкаләтле) затның фамилиясе, телдән мөрәҗәгатьнең эчтәлеге һәм аның буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш. Күрсәтелгән реквизитлар башка кирәкле мәгълүматлар белән тулыландырылырга мөмкин.

6.4. Шәхси кабул итү вакытында граждан шәхесен таныклаучы документны күрсәтә. Граждан мондый документны күрсәтүдән баш тарткан очракта, аның мөрәҗәгате аноним буларак карала.

6.5. Кабул итүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи (яки вәкаләтле) зат гражданны игътибар белән тыңларга һәм аның мөрәҗәгатенең асылын җентекләп тикшерергә тиеш. Әгәр телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм хәлләр ачык булса һәм өстәмә тикшерү таләп итмәсә, мөрәҗәгатькә җавап граждан ризалыгы белән шәхси кабул итү барышында телдән бирелергә мөмкин, бу хакта гражданны шәхси кабул итү карточкасында языла һәм граждан имзасы белән раслана. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап бирелә.

Әгәр мөрәҗәгатьтә хәл ителеше компетенциягә керми торган мәсьәләләр булса, гражданга аңлатма бирелә: аңа кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Әгәр гражданга элек мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелгән булса, шәхси кабул итү барышында мөрәҗәгатьне алга таба караудан баш тартырга мөмкин.

6.6. Вазыйфаи затлар гражданнарны шәхси кабул итүгә бәйле мәсьәләләр буенча башка җирле үзидарә органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә яки оешмаларга мөрәҗәгать итәргә хокуклы, аларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре аларга ярдәм күрсәтергә бурычлы: кирәкле белешмә һәм мәгълүмати материаллар (норматив хокукый актлар нигезендә хәбәр ителергә тиеш булмаган мәгълүматлардан тыш) тапшырырга, квалификацияле консультацияләр, элемтә белән тәэмин итәргә, кабул итү өчен хезмәткәрләрне җибәрергә һ.б.

6.7. Граждан кабул итү бүлмәсендә әйләнә-тирәдәгеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч тудыручы гамәлләр кылган очракта, кабул итүне алып баручы вазыйфаи (яисә вәкаләтле) зат Россия Федерациясе законнары нигезендә тиешле чаралар күрә. Кирәк булганда, эчке эшләр органнары һәм ашыгыч медицина ярдәме хезмәткәрләре чакырыла.

6.8. Органнарда гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына ия:

1) I, II төркем инвалидлар һәм (яки) аларның законлы вәкилләре (ата-ананың берсе, уллыкка алучылар, опекун яки попечитель);

2) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Герое, сугыш хәрәкәтләре ветераннары;

3) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать иткән вәкилләр;

4) кабул итүгә өч яшькә кадәрге балалар белән килгән гражданнар.

6.9. Шәхси кабул итү вакытында 1-4 пунктларда күрсәтелгән гражданнар беренче чиратта шәхси кабул итү хокукын раслаучы документны күрсәтәләр.

6.10. Органнар җитәкчеләре беренче чиратта шәхси кабул итүгә хокукы булган гражданнарның өстәмә категорияләрен билгели алалар.

6.11. Беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына бер үк вакытта берничә граждан ия булса, күрсәтелгән гражданнарны кабул итү аларның шәхси кабул итүгә килүе тәртибендә гамәлгә ашырыла.

## 7. Мөрәҗәгатьләр белән эшләү торышын тикшерү һәм аларны карауны контрольдә тоту. Мөрәҗәгатьләрдә булган мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү

7.1. Органнар һәм вазыйфаи затлар үз компетенциясе чикләрендә мөрәҗәгатьләрне карау тәртибенең үтәлешен контрольдә тоталар, кергән мөрәҗәгатьләрнең эчтәлеген анализлыйлар, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу сәбәпләрен үз вакытында ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрәләр.

7.2. Барлык язмача мөрәҗәгатьләр, шулай ук гражданнарны шәхси кабул итү вакытындагы мөрәҗәгатьләр үтәлү сроклары буенча контрольдә булырга тиеш, аларны карау нәтижәләре турында авторга җавап бирү яки тиешле орган яисә вазыйфаи зат запросы буенча мәгълүмат бирү таләп ителә.

7.3. Турыдан-туры контроль буенча эш Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләнә.

Мондый контрольне гамәлгә ашыручы затлар хокуклы:

а) башкаручылардан һәм аларның турыдан-туры җитәкчеләреннән мөрәҗәгатьләрне карау барышы турында кирәкле мәгълүматларны соратып алырга;

б) билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгатьләрне карау торышын чагылдыручы материаллар белән танышырга;

в) тиешле вазыйфаи затларга мөрәҗәгатьләрне карауны тикшерү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

7.4. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре керүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатында, еллык хисапны әзерләгәндә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә гомумиләштерү һәм анализ ясала. Күрсәтелгән анализда кергән, бүтән адрес белән җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнен, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрнең саны турында, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләр тематикасы турында мәгълүмат булырга тиеш.

7.5. Мөрәҗәгатьләр белән эшләүнең торышы (гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ) Сәмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең еллык хисабында чагыла һәм бирелгән форма буенча Интернет челтәрендә Сәмәкәй авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырыла (3 нче кушымта).

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибенә 1 нче кушымта

Гражданнарны кабул итүне теркәү журналы

| № | ФИАи, туган елы | Эш урыны | Адресы, телефон номеры | Сорауның эчтәлеге | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибенә 2 нче кушымта

**СӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КИЛҮЧЕНЕҢ ШӘХСИ КАРТОЧКАСЫ**

ФИАи ________________________________________________

Яшәү урыны__________________________________________

Социаль хәле_______________________________________

Ташламалы состав____________________________________

Мөрәҗәгать итү датасы «___»_____________202__ел, журналда теркәү номеры __________________

Сорау темасы________________________________________

Әлеге сорау буенча беренче тапкыр, кабат мөрәҗәгать итә__________________________

*(кирәклесенең астына сызарга, әгәр мөрәҗәгать кабатланса, алдагы мөрәҗәгатьнең датасын күрсәтергә)*

Сорауның кыскача эчтәлеге____________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________

Җитәкченең күрсәтмәләре______________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

___________________________________________

Мөрәҗәгать буенча нәтиҗәләр__________________________

______________________________________________________

______________________________________________________

_______________________________________________

Әңгәмәне алып барды _________________________________

Телдән җавапка риза ______________

«___»___________202__ел

_____________________

*(имза)*

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш тәртибенә
3 нче кушымта

# Сәмәкәй авыл жирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында статистик мәгълүматлар

| Мәгълүмат исеме | Цифрлы мәгълүматлар | |
|---|---|---|
| | _______ел | ______ел |
| Барлык кергән мөрәҗәгатьләр<br>(хат, шәхси кабул итү, электрон мөрәҗәгатьләр) | | |
| шул исәптән электрон мөрәҗәгатьләр (Интернет, электрон почта) | | |
| Шул исәптән шәхси кабул итүдә кабул ителде: | | |
| Контрольгә алынды | | |
| Уңай хәл ителде | | |
| Урынга чыгу белән тикшерелде | | |